**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 19 октябрь № 765

г. Казань

«Татарстан Республикасы торак фонды белән идарә итү һәм автоном эшчәнлек төрләрен үстерү дирекциясе» дәүләт бюджет учреждениесен ябу турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы башкара торган «Татарстан Республикасы торак фонды белән идарә итү һәм автоном эшчәнлек төрләрен үстерү дирекциясе» дәүләт бюджет учреждениесен (алга таба – Учреждение) ябу турында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

14 көн эчендә:

Учреждениене ябу комиссиясе составын расларга;

Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә Учреждениене ябу тәртибен һәм вакытларын билгеләргә;

Учреждениене ябу турында карар кабул ителгәннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә теркәү органына, Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертү өчен, Учреждение ябылу процессында тора дигән мәгълүматлар тапшырырга;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына Учреждение ябылу процессында тора дигән мәгълүматлар керткәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен, шул исәптән Учреждениегә оператив идарә итү хокукында беркетелгән күчемсез һәм аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне алга таба яңадан бүлү турында карар кабул итәргә;

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә Учреждениене ябу нәтиҗәсендә эштән чыгарыла торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә, Учреждениене ябу буенча законнарда каралган башка чараларны гамәлгә ашырырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков